Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» ноябрь, 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Таулык авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**«-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Таулык авылының Үзәк урамындагы юл чокырларын ремонтлау) »**

2. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Таулык авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов

Совет
ТЛЯНЧЕ-ТАМАКСКОГО
сельского поселения